КУРКЫНЫЧ ИПТӘШ

Дүрт аяклы дусларның да усаллары була

> 2

БУРЫЧ ЙӨГЕ

Татарстанның суд приставлары, бурычларны түләтү өчен, өйдән-өйгә йөри

> 2



ТАТАРЧА СУПЕРГЕРОЙ

Милли китапханәдә «Туган Батыр» китабын тәкъдим иттеләр

> 3

ХА-ХА-ХАНӘ

Кызык-мызык, булмас димә, фототөрткеләр – монда

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 121 (28894) | Шимбә | 20 август | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Сәрия МИФТАХОВА

ТӘРТИПЛЕ БУЛ, БАЛАМ!

Яңа уку елында мәктәпләрдә дәүләт әләмнәре күтәрелә, атна саен «Мөһим сөйләшү» дәресләре үткәрелә башлаячак. Бу яңалыкларны Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин мәгариф хезмәткәрләренең Яшел Үзәндә узган республика август киңәшмәсендә җиткерде. Чарада белем бирүдән бигрәк, тәрбия турында сөйләштеләр.

Белемсез ничәне егар?

Татарстанда соңгы биш елда 41 мәктәп төзелгән. Быел 11 белем йорты ачылса, шуларның 9ы яңа уку елында ишекләрен ачачак. Укучылар өчен барлык шартлар тудырылган. Мондый мәктәпләрдә яхшы укымау – үзе бер гөнаһ. Өлкәннәр шулай ди. Тик балаларның барысы да болай уйламый. Узган уку елындагы кебек быел да БДИда чик баллны үтә алмаучы балалар бар. Күбесенең химия һәм биология фәннәренә теше үтмәгән. Мәктәпләр арасында «кара исемлек»тә Казанның 41 нче мәктәбе беренче урында тора. Монда укучыларның 26 проценты имтиханны начар тапшырган. Бөгелмәнең кадетлар мәктәп-интернатында андыйлар – 17, Ютазы районының Урыссу бистәсендәге 2 нче мәктәбендә – 15 процент. Илсур Һадиуллин, бу районнардагы мәгариф идарәсе башлыкларына әлеге мәктәпләрдә укытуны көчәйтү буенча эш планнары төзергә йөкләмә бирде.

Министр медалистлар арасында үз белемнәрен акламаганнар турында да сүз кузгатты. Балалардан бигрәк мәктәп җитәкчеләренә, укытучыларга кызарырга урын бар. Бер караганда, мәктәпне «5ле»гә тәмамлаучылар саны узган елдагыдан 13 процентка күбрәк тә. Әмма алган белемнең медальгә лаек икәнен күрсәтә алмаганнар. Ютазы районында медалистларның – 36, Тукай районында – 31, Әлки районында – 25, Буа районында 23 проценты белемнәрен аклый алмаган. Әлмәтнең 17 нче мәктәбендә 6 укучының бары икесе, Казанның 11 нче гимназиясендә 4 укучының берсе генә лаеклы дип табылган.

Сүз уңаеннан, зур киңәшмә башланыр алдыннан Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов БДИда 200 балл туплаучы укучылар белән очрашты. Аларның саны – 14.

– Әлеге яшьләрнең яртысы Мәскәү һәм Санкт-Петербург вузларында укыячак. Бер яктан, аларны кызыктыра алмадык дип үкенәбез, икенче яктан, илнең алдынгы вузларында белем алулары мөһим. Иң кирәклесе – Татарстанга кире әйләнеп кайтуыгыз, – диде Президент.

Аерым бер фәлсәфә

Утырышта Рөстәм Миңнеханов «Адымнар» күптелле белем бирү комплексларына һәм «Сәләт» хәрәкәте эшчәнлегенә зур өметләр баглавын әйтте. Бүген республикада дүрт комплекс эшли. Яңа уку елында Түбән Кама һәм Әлмәттә тагын икесе үз ишекләрен ачачак.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Президент Рөстәм Миңнеханов «Мәктәпкә җыенырга ярдәм ит!» акциясендә 1 нче сыйныфка баручы 20 сабыйга портфельләр һәм мәктәп кирәк-яраклары тапшырды. «Бик кирәкле акция бу. Быел республикада беренче сыйныфка 55 мең бала бару – сөенечле күренеш. Бөтен әти-әниләрнең балаларын мәктәпкә тиешенчә әзерләргә мөмкинлеге юк. Шуңа күрә мондый акцияне уздыру мөһим. Бу чарага үз өлешен кертүчеләргә рәхмәтемне белдерәм, – диде ул һәм үзенең балачагын искә алды. – Безнең бистәдә дусларым 1 сентябрьдә мәктәпкә китте, ә миңа алты яшь иде. Һәм мин дә мәктәпкә барырга булдым. Тик портфелем дә, бернәрсәм дә юк. Абыйның иске булса да, әйбәт портфеле бар иде. Шуның белән 1 нче сыйныфка барган идем».

– «Адымнар» мәктәбе – яңа эш форматы, заманча күптелле мәктәпнең аерым бер фәлсәфәсе, – диде Президент. – Үз илеңнең патриоты булу – туган ягыңны, телеңне ярату, тарихи үткәнне хөрмәтләү. Республикада туган телләр һәм әдәбиятларны өйрәнү өчен шартлар тудырылган. Безнең бурыч – яңа буын дәреслекләр әзерләүне дәвам иттерү, беренче чиратта, татар телендә һәм республикада яшәүче башка халыклар телләрендә дә булдыру.

Тәрбия ни хәлдә?

Быел август киңәшмәсе «Цифрлаштыру чорында тәрбия һәм белем бирү: традицияләрне саклап, киләчәккә барабыз» дигән темага багышланган инде. Мәктәпләрдә БДИ артыннан гына куалар, тәрбиягә урын калмады, дигән сүзләрдә дә хаклык юк түгел. Әхлакны, ватанпәрвәрлек хисен ныгытуны күздә тотып, киләсе уку елыннан укучылар һәр атнаның дүшәмбесендә, ягъни беренче дәрестә дәүләт символлары, патриотик тәрбия турында сөйләшә башлаячаклар. Әлеге үзгәрешләр уңаеннан Илсур Һадиуллин педагогик коллективларга: «Яңа уку елына санаулы көннәр генә калып бара, дәресләрнең темасын барларга, линейкаларны үткәрү тәртибен билгеләргә кирәк», – дип искәртте.

Балаларның зур проблемалары турында да сөйләделәр конференциядә. Сүз тәртип бозучы үсмерләр турында бара. Министр әйтүенчә, бу төркем балалар булган мәктәпләрдә алар өчен аерым программалар булдырылган. Бу – иң күп хокук бозу очраклары теркәлгән, шул ук вакытта психолог ярдәме түбән булган 62 мәктәп һәм урта һөнәри уку йортлары.

Ахыры 2 нче биттә >

Беренче өлеше – быел

Казан – Екатеринбург трассасы төзелешенә 260 миллиард сум акча бүленәчәк. Россия Хөкүмәте Рәисе Михаил Мишустин шул хакта карар имзалаган. Бу хакта М12 трассасы төзелеше буенча штаб утырышында Россия вице-премьеры Марат Хөснуллин хәбәр итте. «Кичә Тверь аша әйләнгеч юл төзүгә – 150 миллиард сум, Казан – Екатеринбург трассасы төзелешенә 260 миллиард сум акча бүлеп бирү турында карар имзаланды», – дип белдерде ул.

Вице-премьер сүзләренә караганда, хәзер биредә әзерлек эшләре башланган. Кичә Марат Хөснуллин «Росавтодор» федераль юл агентлыгы белгечләре белән очкычта трассаның Татарстан, Башкортстан, Пермь краена кергән өлешләрендә эш барышы белән танышты. Марат Хөснуллин сүзләренә караганда, Михаил Мишустин М12 трассасының паспортын раслау турында да карар имзалаган. «Быел безгә Милли байлык фондыннан өстәмә 150 миллиард сум акча да бүленәчәк. Катлаулы икътисади вазгыять хөкем сөрүгә карамастан, шундый карар кабул ителде», – ди вице-премьер.

Хөснуллин әйтүенчә, быел М12 трассасының беренче өлеше эшли башлаячак. «Быел, күздә тотылганнан бер елга алданрак, М12 юлының 100 чакрымга якын озынлыктагы беренче өлешен «эшләтә» башларга тиешбез», – диде Марат Хөснуллин киңәшмәдә. Ул 2023 елда Мәскәү – Казан юлының төп өлешен кулланышка тапшырырга җыенуларын искәртте.

Яңа IT-парк ачыла

30 августта Казанда Бәшир Рәмиев исемендәге яңа IT-парк ачыла. Татарстан цифрлы үсеш министры Айрат Хәйруллин үзенең телеграм-каналында хәбәр иткәнчә, IT-паркның гомуми мәйданы 49700 кв. м тәшкил итәчәк. Министр әйтүенчә, яңа паркта резидентлар өчен зур мөмкинлекләр ачыла. Биредә, аерым алганда, киберарена, криптополигон, балалар өчен зур IT-парк, тәрәзәләре Кабан күленә карап торган сөйләшүләр алып бару залы, 600 кеше сыйдырышлы матбугат залы, 108 эш урынына исәпләнгән зал булачак.

Яңа IT-парк Казан үзәгендә, элекке «Спартак» фабрикасы урынында, Спартак урамы белән Сәлимҗанов урамы арасында урнашачак. IT-парк ике блоктан торачак. Беренчесе «Спартак» фабрикасы бинасын тулысынча яңартуны күздә тота. Икенчесе 3–5 катлы яңа бинадан гыйбарәт булачак. Блоклар бер-берсенә тоташтырылачак, алар арасында амфитеатр элементлары белән җәмәгать урыны булдырылачак. Яңа IT-парк мәйданы буенча Мәскәүнекеннән генә калыша. Проектны гамәлгә ашыруга 4 миллиард сум чамасы каралган.

Чамалап кына бирәбез

Россия Хөкүмәте катыргы һәм кәгазьне чит илләргә чыгаруга квота кертү турында карар кабул иткән. Премьер-министр Михаил Мишустин тиешле карарга кул куйган. Бу чара 3 сентябрьдән 3 декабрьгә кадәр гамәлдә булачак. Квота 30 мең тонна тәшкил итә. Экспортерларга күпмешәр кәгазь җибәреләсен Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы 31 августка кадәр хәл итәргә тиеш.

Карар макулатураны төп чимал сыйфатында кулланучыларга – илебезнең катыргы тартма җитештерүчеләренә ярдәм йөзеннән кабул ителгән. Квота билгеләү шулай ук эчке базарда бу чималга кытлык барлыкка килүгә юл куймаячак.

Сүз уңаеннан, март аенда Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы илдә офис кәгазенә кытлык булмаячагын белдерде. Үзебезнең җитештерүчеләр әлеге кәгазьгә ихтыяҗны тулысынча каплый.

Их, яллар!

Җәй башыннан төрле формадагы 1527 лагерьда барлыгы 152286 балага ял итү насыйп булган. Планның 83 процентын тәшкил итә бу. Соңгы мәгълүматлар буенча, республика территориясендә 100 лагерьда – 15110, шулай ук республикадан читтәге 5 лагерьда 706 бала ял итә. Хәзерге вакытта лагерьларда дүртенче, бишенче сменалар гөрли. Министрлар Кабинетында вице-премьер Ләйлә Фазлыева рәислегендә балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча ведомствоара комиссия утырышында шундый саннар җиткерделәр.

Яшьләр эшләре министрының беренче урынбасары Ринат Садыйков әйтүенчә, ял программасы социаль юнәлешле булуын саклап кала. Быел авыр тормышлы гаиләләрдә тәрбияләнүче, мөмкинлекләре чикле балаларга 42 меңнән артык бушлай юллама бирелгән.

Ләйлә Фазлыева сүзләренә караганда, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов ял һәм савыктыру программасын финанслау нормативын 18 процентка арттыру тәкъдимен хуплаган. Шулай итеп, 2023 елда бу максатка акча күләме, 327 миллион сумга артып, 2 миллиард 132 миллион сумга җитәчәк.

COVID-19

Үзебездән тора

КОРОНАВИРУС БЕЛӘН ҖИҢЕЛЧӘ, ӘММА КҮП КЕШЕ АВЫРЫЙ

Соңгы атнада Татарстанда коронавирус белән чирләү күрсәткече 30 процентка арткан. Көз якынлашканы сизелә: башка чирләр дә тарала башлады. Әйтик, хәзерге көнгә риновирус, аденовирус, парагрипп кебек инфекцияләр күрсәткече 15 процентка җиткән. Белгечләр сәламәтлекне алдан ук кайгыртырга кирәклеген искәртә.

Соңгы тәүлектә коронавирус инфекциясен 109 кеше йоктырган. Саны сагайтса да, чирне сырхаулар җиңел формада кичерә. 95 процент очракта ул кискен респиратор вируслы инфекция кебек узып китә. Димәк, хастаханәгә ятучылар да азрак. Барлык очракларның иң күбе «омикрон» штаммына туры килә икән.

pixabay.com

Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе башлыгы урынбасары Любовь Авдонина халыкка вакцинация хакында онытмаска киңәш итте. Күпләрнең инде беренче тапкыр ясатканнан соң ярты ел гына түгел, бер елдан артык вакыты узган. Моннан тыш гриппка каршы прививка кадатуның да хәстәрен алдан күрәсе.

Татарстанның сәламәтлек саклау министры урынбасары Владимир Жаворонков сүзләренчә, халык кабат вакцина ясатырга ашыкмый. Прививкалылар рәтендә өлкәннәрнең аз булуы да борчый.

– Хәзерге көндә вакцинаның беренче компонентын ясатучылар саны барлык халыкның 86,33 процентын тәшкил итә. 2 млн 630 мең кеше – беренче компонентны, 2 млн 490 мең кеше вакцинаның икенче компонентын ясатты, – диде министр урынбасары. – Шунысы да бар: 1 миллионнан артык кеше ревакцинация узарга тиеш, ә аны 379 мең кеше генә ясатты әле. Үз сәламәтлеген кайгырткан кеше моңа игътибар итсен иде.

Сүз уңаеннан, «Спутник М» балалар вакцинасын республикада яшәүче 6,5 мең балага ясаганнар. Вакцинаның барысын да кулланып бетергәннәр.

Күпләрне «Мәҗбүри вакцинация булырмы-юкмы?» дигән сорау борчыйдыр. Любовь Авдонина сүзләренчә, халыкның аерым категорияләренә коронавирустан мәҗбүри вакцинация ясатуны кертергә җыенмыйлар.

– Әлегә мондый ихтыяҗ юк. Без прививканың кайчан ясалырга тиешлеген аңлаттык, шуңа күрә республикада яшәүчеләрнең аңлы булуына, сәламәтлеген саклау турында кайгыртуларына өметләнәбез, – диде ул.

Роспотребнадзор белгечләре республика халкына битлек киеп йөрергә киңәш итте. Любовь Авдонина искәрткәнчә, республикада хезмәт коллективларында иртәнге фильтрлар үткәрү, дезинфекция, биналарны җилләтү кебек профилактик кагыйдәләрне үтәү дә мөһим.

Сүзгә-сүз

dumrt.ru

Җәлил хәзрәт ФАЗЛЫЕВ, Татарстанның баш казые:

Һөнәр, дибез. Бала мал янына да чыкмый, бакчада да эшләми. Хәтта мәктәптә дә идән юдырырга, тузан сөрттерергә ярамый икән. Ул нинди законнардыр – белмим. Һөнәрсез бала яши алмый бит инде ул, бигрәк тә авыл җирендә. Сабый утырткан орлыкның тишелеп чыкканын, үскәнен, җимеш биргәнен күреп, шуңа сөенергә тиеш. Һөнәрле булырга, җирне яратырга кирәк.

(«Интертат»)

БӘХЕТ ӨЧЕН НӘРСӘ КИРӘК?

Россия халкына бәхет өчен ни кирәк? «Работа.ру» һәм СБЕР ЕАПТЕКА хезмәте белгечләре шул хакта сорашкан.



ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Кичәге романтика һәм бүгенге «практика»

Август аеның өченче якшәмбесендә (быел ул 21 августка туры килә) Россия һава флоты көне (Авиация көне) билгеләп үтелә. Очучылар, стюардессалар, авиадиспетчерлар, самолетларны төзек тотучы инженер-техник хезмәткәрләр, аэропортларда төрле вазыйфаларда эшләүчеләр бәйрәме. Әлеге датаны шулай ук авиация заводларында хезмәт куючылар, шул юнәлештәге конструкторлык бюролары хезмәткәрләре, авиация институтларында укытучылар һәм укучы студентлар да билгеләп үтә. Фәкыйрегез дә әлеге көнне үзенчә билгеләмичә калмый...

Без романтик чорда үстек. Шуңа микән, мәктәптә укыганда бөтен хыялым очучы булу иде. Хәрби очучы, кемнеңдер башына бомба ташлау өчен штурвал артына утыручы түгел, пассажирлар белән тулы зур авиалайнерны һавага күтәрүче. Халыкара авиалинияләрдә рейслар башкарып, илдән илгә, кыйтгадан кыйтгага очучы. Хыялымны, беркем белән дә бүлешмичә, сер итеп, әллә ничә ел эчемдә саклап йөрдем. Ләкин, ни кызганыч, язмышның мин белмәгән нindидер шаяруы, шуклыгы аркасында, мәктәпне бетергәнче үк, хыял белән хушлашырга туры килде.

«Хөкем карары» башка көтмәгәндә ишелде. Өлкән сыйныфларда чакта, җәйге каникул вакытында шәһәргә экскурсиягә баргач, барыбызны да карусель дигән, авыл баласы күрмәгән хикмәткә утырттылыр. Менә шуның утыргычыннан төшкәндә, бөтен дөнья минем тирәли ярсып әйләнә һәм нык кына укшыта иде. Укытучылар да сизде хәлемне. Берсе, шаярткан булып: «Да-а, летчик чыкмый икән синнән», – дип куйды. Бу сүзләргә ул чакта артык игътибар итмәсәм дә, соңыннан уйлый-уйлый, укытучыбызның хаклы булуын төшендем: вестибуляр аппаратың төзек түгел икән, штурвалга якын киләм димә инде. Әмма хыял җимерелсә дә, авиациягә мәхәббәт сүрелмәде. Самолетларга, авиациягә якынрак буласы килептер инде, мәктәпне тәмамлауга, КАИга юл тоттым.

Инде укып чыкканга да байтак еллар үтте. Малай чакның беркайчан да тормышка ашмаячак хыялы күңелне элеккечә җилкетмәсә дә, «яраплан»га мәхәббәт, беренче мәхәббәт кебек, күңелдә әле. Зур авиалайнерның пошмый гына очу полосасыннан күтәрелеп маташканын яисә, киресенчә, закрылкаларын аска җәеп җибәреп төшкәнен телевизорда яки компьютер экранында гына күрсәм дә, һич тыныч кала алмыйм, дулкынланып күзәтәм, кайчакта бала йоннарым кабара. Могҗиза бит, бер карасаң – берничә йөз тонна авырлыктагы зур лайнер һавага, бушлыкка күтәрелә, анда оча. Очуның физикасын, хикмәтен белсәм, аңласам да, күренеш минем өчен һаман да могҗиза булып кала.

Авиация институтында очу эше – пилотированиегә, әлбәттә инде, өйрәтмиләр. Шуңа да карамастан, мин, хыялый, аны күпмедер беләм. Беләм дип уйлыйм, чөнки ул хакта кайда нинди мәгълүмат бар, барысын да «йотып», сеңдереп барам. Беркайчан да штурвал артына утырмаячагымны белеп тә тыела алмыйм. Элек тә шулай иде, хәзер дә. Лайнер кабинасын бер генә тапкыр күргән кеше дә анда йөзәрләгән прибор, тумблер, кечкенә һәм зур рычаглар, кнопка-төймәләр барлыгын белә. Мин дә аларның күбесенең урынын, билгеләнешен, кайсы вакытта кая таба борырга, күтәрелгәндә нинди гамәлләр башкарырга, төшкәндә ниләр кылырга кирәклекне беләм. Кирәге чыкмасын белсәм дә беләм. Менә шундый практикасы булмаган һәм инде булмаячак хыялый теоретик. Тик теориянең дә, хыялның да әле беркемгә комачаулаганы юк, андый романтизм миңа, киресенчә, рәхәтлек кенә китерә, шатландыра, яшәү көче өсти...

Совет чорында Авиация көне өченче якшәмбегә бәйләнмәгән, ул ел саен бер үк көнне – 18 августта бәйрәм ителә иде. Ул чакта ил дә башка, ул авиация державасы санала иде. Малай-шалайның да башкалыгын әйттем инде. Гражданнар авиациясендә дистәләгән төр, марка самолетлар. Ан-24, Як-40тан башлап алагаем Ту-154, Ил-62гә чаклы барысы да – иң гади деталенә, соңгы заклепкасына чаклы үзебездә эшләнгән очкычлар. Кечерәк шәһәрләрдә дә гөрләп эшләп торган аэропортлар. Узган гасырның 70–80 нче елларында шул ук Бөгелмә аэропортыннан Казанга көн саен 7–8 рейс башкарылды. Сигез тәңкәгә билет алып, самолетка кереп утырасың да 45–50 минуттан син мәркәз калада. Башкортстанның мин туган авылдан 15 чакрымда гына урнашкан Октябрьский шәһәре аша да кайтып-китеп була иде. Аэропортлары Ыкның бу ягында, Татарстан биләмәләрендә урнашкан. Казан тикле Казаннан туры үз авылыңа килеп төшкән сыман...

Капитализмга кергәч, акча саный башлагач, ул рәхәтлекләр бетте. Совет илендә эшләнгән самолетларның «коточкыч» кимчелеге ачылды. Чит ил очкычлары белән чагыштырганда, аларның аппетиты артык зур – ягулыкны күп ашыйлар икән бит. Авиасәнәгать нык алга киткән илдә ул җитешсезлекне төзәтү зур чыгымнар сорамагандыр, дип уйлыйм. Әмма нефть долларлары елга булып акканда, нигә андый «начар» авиапарк, нигә самолет ясап мәшәкатьләнергә? Сатып кына аласы да очасы – төрле зурлыктагы, төрле модификациядәге Ту, Ил, Ан, Якларны «Боинг», «Аэробус»лар алыштырды. Күпме ягулык янга калгандыр, әйтү кыен, тик менә дистәләгән авиазаводларның меңәрләгән эшчеләре эшсез калды. Ил дә авиация державасы булудан туктады. Бүген хәл тагын да мөшкелрәк: санкция-чикләүләр аркасында, чит ил очкычларыннан торган авиапарк запас частьларсыз утыра. Самолетларга хезмәт күрсәтүче чит ил персоналы, белгечләр дә өйләренә кайтып китте. Бүген әйләнешкә «авиация каннибализмы» дигән төшенчә кереп маташа. Ул сүз бер очкыч очсын өчен икенче шундый ук очкычны запас частьларга ботарлауны аңлата. 80–100 млн доллар торган «Боинг 737»не, запчасть кирәк дип, сүтеп ташлауны күз алдына китерегез әле. Әмма сүтәләр, чөнки бортларның өчтән бере тик тора. Ни өчен тора, дигәндә дә җавап билгеле кебек.

Бу юлларны язганда, илдә авиадиспетчерларның яртысына якыны ялда булуы турындагы хәбәр килеп ирешге. Очучылар да шундыйрак проблема кичерә, дип уйлау дөрестер. Чөнки февраль азагы, март башыннан бирле бик күп халыкара рейслар ябылды. Европа кыйтгасы өстенә һәм Төньяк Америка күгенә Россия самолетларын гомумән дә кертмиләр. Без дә җавап йөзеннән аларныкын үткәрмибез. Ул гынамы, илебезнең көньягына урнашкан 11 зур аэропорт инде ярты елга якын эшләми. Пассажир самолетын хәрби очкыч, бигрәк тә хәрби-транспорт борты белән бутау очраклары кораллы конфликт барган урыннарда еш була торган хәл – бәласеннән башаяк. Җыеп әйткәндә, романтизм кимеп, күктән җиргә төшкән вакытлар бүген...

ТӘРТИПЛЕ БУЛ, БАЛАМ!

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

– Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә уздырылган күзәтүләргә таянып, Казанның 180 нче гимназиясендә, 8 нче мәктәбендә, Түбән Каманың 7 нче мәктәбендә, башкаланың төзелеш көллиятендә проблемалы урыннарны барладык. Шул ук вакытта башкаланың 174 нче гимназиясендә, Түбән Кама педагогик көллиятендә «хәвефле төркем»гә кергән үсмерләр белән эшләүнең нәтиҗәле юллары билгеләнде, – ди Илсур Һадиуллин.

Татарстан буенча эчке эшләр министры Артем Хохорин белдергәнчә, полициядә исәптә 2500ләп бала тора. Соңгы елда җинаятьләр саны кимү күзәтелә. Татарстанда күрелә торган чаралар нәтиҗәсе бу. Әмма кылганнары бер дә балаларча түгел. Үсмерләр эшләгән җинаятьләрнең өчтән бере – үтерү, талау, урлау кебек очраклар. Әйтик, Спас районында бер укучы һәм студент аның әнисе белән бергә яшәгән ир-атны үтергән. Август аенда Яшел Үзән районында үсмерләр пиццериядә сатучыны кыйнаганнар. «Актив һәм үзен күрсәтә белгән яшьләр генә түгел, игътибардан читтә калган үсмерләр белән дә эшләргә кирәк», – диде генерал Хохорин утырышта.

Президент Рөстәм Миңнеханов та үсеп килүче буында рухи-әхлакый кыйммәтләргә игътибарны арттырырга кушты. «Төп бурыч – балалар һәм яшьләр белән эшләүгә игътибар», – диде ул. Шулай ук тәрбия эшендә ата-аналар белән тиешенчә эшләү кирәклеген искәртте, тәрбия эшендә сыйныф җитәкчесе роленең дә зур икәнлеген билгеләп узды.

– Быел Россиянең Мәгърифәт министрлыгы сыйныф җитәкчесе белән актуаль темалар буенча сөйләшүләр проектын гамәлгә кертте. Яшьләрдә патриотизм һәм гражданлык хисе тәрбияләргә кирәк, – диде ул.

Һәр тармак үз эчендә эшли...

Татарстан яшьләр эшләре министры Тимур Сөләйманов яшьләр белән эшләү алымнары турында сөйләде. Аның әйтүенчә, республикада 750дән артык балалар оешмасы эшли. Ел саен мәктәп, авыл һәм район оешмалары чараларында 300 меңнән артык бала һәм үсмер катнаша. Узган ел белән чагыштырганда, балалар оешмаларының саны шулай ук арткан (2020 елда – 694, 2021 елда – 766). Зәй районында 1дән 63кә, Менделеевскида 11дән 37гә, Чирмешән районында 40тан 60ка кадәр арткан.

«Юнармия» хәрби-патриотик хәрәкәтендә 35 меңнән артык бала катнаша. Республиканың 29 районында 135 хәрби-патриотик клуб эшчәнлегенә 13 мең бала һәм яшүсмер җәлеп ителгән.

– Шул ук вакытта, без бу өлкәдәге эшләрнең торышыннан тулаем канәгать, дип әйтү дөрес булмас иде. Ел саен Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә белем бирү мохитенең куркынычсызлыгын мониторинглау безгә 800дән артык «проблемалы» баланы ачыкларга мөмкинлек бирә, – диде Тимур Сөләйманов. – Челтәрләрне күзәтү «АУЕ» яки суицидаль-депрессив төркемнәр кебек агымнар белән мавыгучы 600дән артык бала барлыгын күрсәтә. 2219 бала – социаль яктан куркыныч хәлдәге гаиләләр исемлегендә, ә 2400дән артык бала балигъ булмаганнар эшләре бүлекчәләрендә күзәтү астында тора. Тәрбиягә бертөрле караш булмау, куркыныч янаганны теркәп бармау, кызганыч, аяныч нәтиҗәләргә китерә.

Тимур Сөләйманов белдергәнчә, һәр тармак үз инфраструктурасы эчендә эшли. Ә 6 яшьтән 18 яшькә кадәрге балаларның ихтыяҗы бала үскән саен үзгәрә, аның белән аралашу теле дә үзгәреп тора. Еш кына без, шуны алдан күреп, тиешле чарасын күрергә өлгерми калабыз.

Ятимнәрне эшкә урнаштырырга кирәк

Татарстанда 9,5 мең ятим бала исәпләнә, 8,5 меңе тәрбиягә алынган гаиләләрдә яши. 1117 ятим баланың гына яшәү урыннары сакланган, башкалары фатирсыз калган.

– Гаиләләрне күз уңында тоту, имин булмаган гаиләләрне вакытында күзәтеп торуның тиешле дәрәҗәдә булмавын күрсәтә бу. Нигә шулай килеп чыккан? Дәүләт мондый мәсьәләләрне хәл итәргә тиеш, – диде Президент, бу юнәлешкә игътибарны көчәйтергә кушып.

Рөстәм Миңнеханов ятимнәргә бирелгән фатирларда торак-коммуналь түләүләр өчен бурычлар җыелганын һәм мондый хәлнең булырга тиеш түгеллеген әйтте. Аларның 51 млн сум бурычлары җыелган.

– Фатир бирелгән икән, дәүләт хисабына бушлай яши алмыйлар, алар барлык хезмәтләр өчен түләргә тиеш. Төп эш – Казан, Чаллы, Түбән Кама, Яшел Үзәндә. Ятимнәрне эшкә урнаштырырга кирәк, – диде Рөстәм Миңнеханов, район башлыкларына мөрәҗәгать итеп.

ДӘҮЛӘТ ФЛАГЫ КӨНЕ БЕЛӘН!

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит МӨХӘММӘТШИНның Россия Федерациясе Дәүләт флагы көне уңаеннан КОТЛАВЫ

Хөрмәтле ватандашлар!

Сезне ихлас күңелдән Россия Федерациясе Дәүләт флагы көне белән котлыйм.

Герб һәм Гимн белән беррәттән дәүләтнең төп символларының берсе булган Россия әләме төсләрендә күпмилләтле халкыбызның рухы һәм ышанычы, какшамас батырлыгы һәм намусы, азатлык һәм гаделлек идеяләренә тугрылыгы кебек тормышның төп принциплары чагылыш тапкан. Дәүләт флагы иң әһәмиятле вакыйгалар вакытында күтәрелә. Халыкара очрашулар һәм сөйләшүләр дә ансыз үтми. Ул россиялеләрнең хезмәттәге һәм фән, икътисад, мәдәният, спорт кебек барлык өлкәләрдәге казанышларын бәйли. Яңа уку елы башыннан патриотик тәрбия бирү һәм тарихи рухи-әхлакый кыйммәтләргә хөрмәт белән карау максатларында илнең барлык мәктәпләрендә һәр атна илебезнең Дәүләт флагын күтәрү һәм Гимнын башкару тантанасыннан башланачак.

Россия Федерациясенең төп көче – аның талантлы һәм тырыш, Ватаныбызның уңышлы һәм якты киләчәге өчен хезмәт куючы халкы. Гражданнар бердәмлеге һәм конфессияара татулык, үзара ышаныч һәм мәдәниятләрнең рухи бөтенлеге, күп гасырлык традицияләрнең һәм гореф-гадәтләрнең буыннан-буынга күчүе, бай табигый һәм интеллектуаль потенциал – болар барысы да безнең киләчәгебезнең ныклы нигезен тәшкил итә. Безне, Татарстан Республикасы халкын, бердәм Россия дәүләте гражданнарын, рухи бергәлек һәм Ватанга тугрылык хисе берләштерә. Бүгенге катлаулы шартларда без милли лидерыбыз – Россия Федерациясе Президенты В.В.Путинга теләктәшлек белдерәбез һәм бердәмлек күрсәтәбез. Ышанам ки, иңне иңгә куеп, без сынауларның барысын да җиңеп чыгачакбыз һәм, барлык уйларыбызны тормышка ашырып, куелган максатларга ирешәчәкбез.

Кадерле дуслар! Россиянең барлык гражданнары өчен, аларның этник һәм социаль хәленә бәйсез рәвештә, аеруча әһәмияткә ия булган әйберләр һәм символлар бар. Алар исәбенә, һичшиксез, илнең төп символик атрибутлары керә. Горур тибрәлгән ак, зәңгәр һәм кызыл төсләрдәге Россия Федерациясе Дәүләт флагы һәркемнең күңелендә Ватаныбыз өчен чиксез горурлык хисләре уятуын телим.

Өйдә – бурыч, бусагада – пристав

Үзем күрдем

Татарстан Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгыннан алынган мәгълүматлар буенча, республика халкының коммуналь хезмәтләр өчен 8 млрд сумнан артык бурычы җыелган. Аны кайтарып алу өчен, бурычлыларның мөлкәтенә, банк карталарына арест салына. Хезмәт хакының күпмедер өлеше дә тотып калырга мөмкин. Милек рәсмиләштерүгә рөхсәт бирмәү, Россиядән чыгуны тыю һәм административ җаваплылыкка тарту да каралган. Суд приставлары бурычлыларның машиналарын да ала.

Быел җиде айда суд приставларында торак-коммуналь хезмәтләргә кагылышлы 35703 эш теркәлгән. Татарстанның суд приставлары бурычларны кайтару өчен өйдән-өйгә йөри. Казанда узган рейдка алар белән бергә «ВТ» журналисты да чыкты. Иң элек без Коләхмәтов урамында яшәүче бер гаиләгә юл тоттык. Беренче катта яшәүче гаиләдә ишекне ачмадылар. Күршеләр ярдәме белән подъезд ишегеннән үтә алсак та, фатирга керә алмадык. Киров районы суд приставларының әйдәп баручы белгече Гүзәл Загиева сүзләренә караганда, биредә яшәүче Хәкимовларның торак-коммуналь хезмәтләр өчен 200 мең сумнан артык бурычы җыелган. Аларга инде беренче генә барулары түгел икән. Әмма һаман да уртак фикергә килә алмыйлар.

Ишек ачканны көткән арада безнең янга күршеләре җыелды. Сүзгә саран булып чыкмадылар. Бишенче катта яшәүче Евгений Матросов сүзләренчә, бурычлыларны фатирдан куарга кирәк. Ә Илназ исемле күршеләре аларның балаларын кызгана. Хәкимовлар гаиләсендә өч кечкенә сабый тәрбияләнә! «Яшь гаилә булсалар да, көн-төн эчәләр. Акча каян алалардыр, белмим. Эчеп яткач, бурыч җыела инде ул», – ди Илназ.

Суд приставлары бу юлы да аларның ишегенә чакыру кәгазе кыстырып китте. Тагын киләсе булачак.

Батыршин урамындагы биш катлы йортларның берсендә яшәүче 56 яшьлек Марина ханым ишекне бер каршылыксыз ачты. Хәлләре мөшкел – аның әҗәте 500 мең сумга җиткән.

– Бик авыр хәлдә калдым. 16 яшемнән эшли башлаган идем. Бик озак еллар пешекче булдым. Кинәт кенә инсульт бәрде. Ирем иртә үлгәч, улымны бер ялгызым үстердем. Бар яхшысын бирергә тырыштым. Тик ул гына туры юлдан тайпылды. 24 яшендә булса да, өченче тапкыр төрмәгә эләкте. Бер ел утырасы калды әле. Кайтыр, ярдәм итәр дияр идең, тик аның иректә торганы да юк, – дип елап җибәрде ул.

Маринаның фатирында күп еллар ремонт булмаганы күренеп тора. Кухнясында тараканнар йөгерешә. Ашарга ризыгым бар, ачтан үлмәс өчен подъезд юам, ди.

– Инсульт булгач, миңа инвалидлык биргәннәр иде. Хәлем уңайлангач, аны алдылар. Әмма һаман дару эчәм. Сәламәтлегем аркасында эш табу кыен. Идән юганыма да сөенеп яшим. Бурычым барлыгын беләм мин. Түләмәү юлларын да эзләмим. Идарәче оешма белән сөйләштем бит инде. Ай саен 1500 сум түләргә дип килешү төзедек. Ә сез нигә дип килдегез? – диде ул.

Баксаң, Марина ханымга, идарәче оешмага барып, кабат гариза язарга кирәк икән. Суд приставлары аның өендәге милеккә арест салдылар.

Ни өчен бурыч җыела? Без бу хакта суд приставларыннан да сораштык. Кемдер хәмер белән дуслаша, берәүләр кинәт авырып китә, икенчеләр эшсез кала. Әмма ваемсызлар да җитәрлек. Әҗәтләләр арасында хәлле кешеләр дә аз түгел. Аларның хәтерен эшләтеп җибәрү өчен, суд приставларының килүе дә җитә. Икенче көнгә үк бурычын түлиләр икән. Без тагын берничә адрес буенча ишек шакыдык. Әмма суд приставларын көтеп тормыйлар, ишек ачучылары бик сирәк.

Димәк, тагын йөрергә, ишек шакырга туры киләчәк. Приставлар әйтүенчә, бер әбинең торак-коммуналь хезмәтләр өчен 1 миллион сумнан артык әҗәте җыелган. Ул пенсиясенә 5 онык үстерә. Бурыч түләргә акчасы калмый.

– Киров районында бурычлылар күп. Быел җиде ай эчендә 701 эш теркәлде. Шуның 402сеннән 11 миллион 600 мең сум бурыч кайтарып алынды, – ди Гүзәл Загиева. – Бер генә теләк: кешеләр әҗәтен вакытында түләсен иде. Авыр тормышта яшәүчеләрнең хәленә керергә тырышабыз. Бурыч килүне туктатыр өчен кая барырга икәнен дә әйтәбез. Тормышта төрле хәлләр була. Бурычка баткан кеше авыр хәлдә калуы турында идарәче оешмага язмача хәбәр итсен, алар белән килешү төзесен иде.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ЭТ ЭТЛЕГЕН ИТӘ

Күпме генә язып торсак та, кызганыч, этләр проблемасы һаман хәл ителми. Бу атнада Кукмара районында булган фаҗига әлеге мәсьәләгә җәмәгатьчелекнең, җитәкчеләрнең һәм тикшерү органнарының игътибарын тагын бер кат юнәлтте.

Фаҗига Кукмара районының Жилой Рудник бистәсендәге балалар мәйданчыгында килеп чыккан. Ул көнне бер урам эте өч балага ташланган. 5 яшьлек Азалия әбисе белән булган, ә 2011 елгы малайлар яшьтәшләре белән уйнап йөргән. Ике малайның да куллары җәрәхәтләнгән. Аларны табиблар, карагач, укол кадап, дәваланыр өчен өйләренә кайтарып җибәргән. Ә менә кечкенә кызчыкның эт битен тешләгән.

Әлеге вакытта Азалия әнисе белән Балалар республика клиник хастаханәсендә дәвалана.

– Балага психолог ярдәме кирәк булачак. Бик куркып калды, төнлә йоклый алмый, сөйләшми, – дигән аның әнисе Эльмира Фатыйхова.

Зур Кукмара авылына да шалтыраттык. Исемен газетада күрсәтергә теләмәгән авыл кешесе әйтүенчә, сукбай этләр – иң зур проблемаларның берсе. Алар күп, киләчәктә тагын да артачак, ди ул.

– Этләрне бит хәзер бернишләтеп тә булмый. Закон юк. Югыйсә биш-алты ел элек, законга үзгәрешләр кергәнче, безнең җирлектә генә дә елына 60лап этне аталар иде. Хәзер моның өчен җаваплы оешма ике атнага бер тапкыр килә, ләкин бу бик аз. Гариза җибәргәч, ике атнадан соң гына да килергә мөмкиннәр. Алай гына җиңә торган проблема түгел бу. Әгәр законга үзгәрешләр кертелмәсә, мондый фаҗигаләр тагын да булачак әле.

Авыл халкы фикеренчә, әлеге эш белән башка шәһәрдәге оешмалар түгел, ә һәр районның үз ветеринария хезмәте шөгыльләнергә тиеш.

– Этләрне аулаучылар вакытында килеп җитә алмый. Алар гына аулап бетерә дә алмый аны. Язын сарыкларны да буып чыккан иде сукбай этләр. Буылган кош-кортлар турында әйтеп тә тормыйбыз инде. Алар бик күп, – диделәр безгә.

Кукмара районында сукбай этләрне аулау белән «Спецгрупп+» оешмасы шөгыльләнә. Соңгы вакытта аларның эшчәнлегенә карата шикаятьләр күп булган. Район хакимиятендә әйтүләренчә, бүлеп бирелгән акчаның күпчелек өлеше әлегә кадәр файдаланылмаган. Кызганыч, оешманың җитәкчесе белән элемтәгә чыга алмадык. Хәзерге вакытта ялда, диделәр.

Балаларга ташланган эткә килгәндә, аны тотканнар һәм районның ветеринария берләшмәсенә китергәннәр. Әлегә үз-үзен тотышын күзәтәләр, тикшерәләр. Хайванның аннан соңгы язмышы билгеле түгел.

Әлеге вакыйга буенча «Ваемсызлык» маддәсе буенча җинаять эше кузгатылган. Эшне тикшерүне Россиянең Тикшерү комитеты башлыгы Александр Бастрыкин үз контроленә алды.

Ике көннән соң шуңа охшаш вакыйга Биектау районының Пановка авылында килеп чыкты. Тик бу юлы кешеләр түгел, ә сарыклар зыян күрде. Фермерның ун баш сарыгын төнлә шулай ук сукбай этләр ботарлаган. Фермер әйтүенчә, шушы ук этләр халыкка, шул исәптән балаларга да берничә тапкыр һөҗүм иткән булган.

Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе мәгълүматы буенча, быел хастаханәләргә 3449 кеше мөрәҗәгать иткән. Аның 949ы – 14 яшькә кадәрге балалар. Татарстандагы иң зур приютларның берсе булган «Зооцентр» оешмасы мәгълүматлары буенча, быел алты ай эчендә алар 2,3 мең сукбай этне аулаган. Моннан тыш, этләр аулау буенча «кайнар линия»гә 3,6 мең шалтырату кабул ителгән.

Озак еллар мал табибы булып эшләгән Илдус Хатыйпов эт һәм песиләрне чиплаштырырга, ягъни учетка куярга кирәк, дигән фикерен тагын бер кат әйтте.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Халык моңа, салымнан куркып, каршы чыга. Ләкин бу проблеманы хәл итәргә ярдәм итәр иде. Һәр этнең паспорты булырга тиеш. Һәм җаваплылык этнең көчеген сатып җибәргән хуҗада калырга тиеш, – ди ул.

Аның фикеренчә, этләрне приютка туплау шулай ук дөрес түгел.

– Чөнки алар яши торган җирдә паразит һәм йогышлы авырулар да арта, – ди ул. – Стерильләштереп урамга җибәрүнең дә мәгънәсе юк, чөнки этләр – өер белән йөри торган хайван һәм алар лидерлык өчен көрәшәчәк. Этләр берничек тә тыныч кына йөри торган җан ияләре түгел. Бу фикер аларны яклаучыларга ошамас, билгеле. Стерильләштерелгән яки кастрация ясалган этләр, песиләрнең бөерләрендә таш барлыкка килә. Димәк, алар урамда барыбер авырый башлаячак. Шуңа күрә хайваннарны шунда ук үтерергәме, әллә урамда авырып җан тәслим кылганын көтәргәме? Мәсьәләнең әнә шул ягы да бар.

Кыскасы, фаҗигасе яңа, проблемасы иске. Сукбай этләрдән зыян күрүчеләр саны көннән-көн артса да, проблеманың тамырына балта чаба торган конкрет чаралар әле дә булса күрелми. Бәлки, сукбай этләрне киметергә яки бөтенләй бетерергә ярдәм итүче закон кайчан булса да кабул ителер, тик аңа кадәр тагын күпме кеше зыян күрер?

Зөһрә САДЫЙКОВА

ЯҢА БАТЫР

ТАТАР БАЛАЛАРЫНА БЭТМЕН БЕЛӘН СУПЕРМЕННЫ КЕМ АЛЫШТЫРЫР?

dumrt.ru

Мин кулыма китап алам

Татарстанның Милли китапханәсендә Зөлфәт Хәким иҗат иткән «Туган Батыр» кыйссасын тәкъдим иттеләр. «Туган авылым» милли комплексын гамәлгә куючы Радик Абдрахманов зур командасы белән берлектә төп герой Туган Батырдан зур проект, бренд ясамакчы. Чөнки татар балаларының үз герое булырга тиеш.

Төп герой – курку белмәс Туган Батыр. Аның иң көчле коралы – акылы, тапкырлыгы. Танылган драматург, прозаик, китапның авторы Зөлфәт Хәким сүзләренә караганда, әсәр аның балачак хатирәләренә нигезләнеп язылган.

– Бик каты авырганнан соң, кайсы эшкә алынырга икән, дип утырганда, әлеге проектның әдәби өлешенә алынырга тәкъдим иттеләр. Геройның нинди булырга тиешлеген аңлатуга, мин ризалаштым. Үземә дә сәер булды ул, чөнки мин уйланыр өчен берникадәр вакыт алам. Күрәсең, проектның әһәмияте шунда ук шәйләнгән, – дип сөйләде ул. – Бик тиз һәм җиңел язылды әсәр. Мин традицион әкиятләрдән махсус читләшергә тырыштым. Аларның күбесе примитив язылган. Билгеле, бу балалар аңласын өчен эшләнгән. Минем исә балалар гына түгел, әтиәниләре өчен дә язасым килде. Һәм язганда балачагымны, авылымны, бергә үскән яхшы һәм начар малайларны искә төшердем.

Китапның беренче өлешендә Туган Батырның 9 яшьтән алып 16 яшькә кадәр тормышы сурәтләнгән. Автор сүзләренчә, аннан идеаль образ ясарга тырышмыйлар.

– Балалар тормышның хаталарсыз булмавын аңлап үсәргә тиеш. Без бит барыбыз да яктылыкка илтә торган сукмак бар икәнен беләбез, ләкин ул сукмактан барыбыз да туры гына бармыйбыз. Хәзерге балалар бик тиз җитлегә, шуңа да аларга башка төрле әсәр кирәк, – дип аңлатты ул.

Кәгазьдә генә түгел

Проектның авторы Радик Абдрахманов журналистларга киләчәккә ниятләре турында сөйләде.

– Бер генә түгел, берничә команданың уртак эше бу. Әлегә «Туган Батыр» беренче адымнарын гына ясый. Ләкин тиздән ул брендка әйләнәчәк. Бүген без өч телдә нәшер ителгән китап тәкъдим итәбез. Шулай ук проектның символикасы төшерелгән киемнәр, сувенирлар да бар. «Туган Батыр» призына уктан ату һәм көрәш турнирлары үткәреләчәк, сентябрьдә «Урам» паркында зур фестиваль көтелә, «Бала-сити»да спорт залы эшли башлаячак, аудиокитаплар яздырылган. Хәзерге вакытта китапның икенче өлеше языла. Киләчәккә дә ниятләребез зурдан. Иң зурларының берсе – күңел ачу паркы булдыру, – диде ул.

Яңа батыр турында мультфильм төшерергә җыена алар. Хәзерге вакытта бөтен дөнья балалары белгән «Маша и медведь» мультфильмын төшерүчеләр белән сөйләшүләр алып баралар. Беренче коймак төерле булырга тиеш түгел. Киресенчә, сыйфатлы проект белән шаккатырмакчы алар.

Хәзер алар үз командасына талантлар эзли. Әйтик, тиздән Туган Батыр риваятьләре комикслар (рәсемнәр рәвешендәге хикәя) форматында тәкъдим ителәчәк. Оста итеп рәсем ясасагыз, рәхим итегез, ди оештыручылар.

Очрашуда Радик Абдрахманов әйтмешли, проектның рухи остазы, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин да бар иде.

– Хәзерге вакытта уртак мәдәниятебезнең бер өлеше формалаша. Безнең балалар «MARVEL», «Disney» мультфильмнарын карап үсә. Алар бит безнең асылыбызга туры килми. Ә балаларыбыз аларга охшарга тырыша, аларны кабатлый, – диде ул. – Без традицион кыйммәтләребезне традицион булмаган фикерләүдән сакларга тиеш дигән фикергә килдек. Безгә үз героебыз, үз батырыбыз кирәк. Балаларыбыз, аңа карап, яхшы үрнәк алырлык булсын. Ә бит татар батырының образы безнең күңелләрдән юкка чыкты. Чал тарихлы халыкның лаеклы батыры да булырга тиеш.

«Туган Батыр» проектын тәкъдим итү кичәсенә мәртәбәле кунаклар да чакырылган иде. Татарстанның халык артисты Миңгол Галиев исә түзмәде, китаптагы рәсемнәргә (баш иллюстратор – Игорь Афанасьев) карата үз фикерен җиткерде. Аның сүзләренчә, андагы образларның сурәтләнеше татар малай-кызларына хас түгел. Бу фикер белән соңыннан Зөлфәт Хәким дә килеште. Авыл малайлары, кызлары йөз-кыяфәткә башкачарак була, дигән фикердә ул да.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

КОТЛЫЙБЫЗ

Илебездә авиатөзелеш тармагын үстерүгә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен «Туполев» гавами акционерлык җәмгыяте филиалы – С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводының 3 нче цехы фрезеровщигы **Григорьев** Вячеслав Анатольевич; «Туполев» гавами акционерлык җәмгыяте филиалы – С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводының технологик җиһазлар җитештерү цехы шомартучысы **Полкова** Светлана Викторовна; нефть сәнәгатен үстерүгә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Консалтинг үзәге» акционерлык җәмгыяте генераль директорының инвестиция проектларын бәяләү буенча урынбасары – инвестиция проектларын бәяләү бүлеге башлыгы **Кәбиров** Линар Әхмәтзаһит улы; В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең Нефть һәм нефть продуктлары сату идарәсе башлыгы урынбасары **Рәхимов** Илгиз Инсаф улы; В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең Татарстан фәнни-тикшеренү һәм проектлау нефть институты нефть ятмаларын үзләштерү бүлегенең тышкы территорияләрдә нефть һәм газ ятмаларын үзләштерүне проектлау һәм Баулы төркеме лабораториясе мөдире **Хәкимҗанов** Илгизәр Нургизәр улы; В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте Бизнеска хезмәт күрсәтү үзәгенең Лениногорск районы буенча социаль программаларны үтәүгә ярдәм итү үзәге җитәкчесе урынбасары **Хәнипов** Ирек Гыймазетдин улы; төзелеш тармагын үстерүгә һәм республиканың сәнәгать потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе өчен «Спецнефтегазпроект» фәнни-тикшеренү һәм проектлау институты акционерлык җәмгыяте генераль директоры **Шәйхетдинов** Азат Альберт улы; илебездә машина төзү тармагын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Лениногорск механика заводы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Якушкин** Олег Елендеевич **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Республиканың нефть сәнәгатен үстерүгә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Геология, нефть эзләү буенча тикшеренү үзәге» акционерлык җәмгыятенең нефть чыгару операторы **Кәлимуллин** Рәшит Минтаһир улы, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте генераль директоры киңәшчесе **Каюмов** Малик Шәфикъ улы, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте Төзелеш проектларын башкару идарәсе төзелешне оештыру хезмәтенең смета бүлеге әйдәүче инженеры **Косолова** Марина Сергеевна, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур бүлекчәсе «Җәлилнефть» нефть чыгару идарәсе нефтьне комплексы әзерләү һәм кудыру цехының скважиналарны капиталь һәм җир астында төзекләндерүгә әзерләү операторы **Низаметдинов** Нәҗип Мөнир улы **«Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан»** медале белән бүләкләнде.

***

В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте хезмәткәрләре: Скважиналарны җир астында төзекләндерү идарәсе скважиналарны җир астында төзекләндерү Җәлил цехының скважиналарны җир астында төзекләндерү операторы **Кәлимуллин** Рим Рифкать улына, «Татнефть-Добыча» структур бүлекчәсе «Әлмәтнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсенең 5 номерлы нефть һәм газ чыгару цехы нефть һәм газ чыгару операторы **Клементьев** Владимир Емельяновичка, Скважиналарны җир астында төзекләндерү идарәсе скважиналарны җир астында төзекләндерү Лениногорск цехының скважиналарны төзекләндерү буенча (капиталь, җир астында) мастеры **Трофимов** Петр Михайловичка **«Татарстан Республикасының атказанган нефтьчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

